**XX гасыр азагы XXI гасыр башы балалар шагыйрьләре иҗатында милли кыйммәтләр чагылышы. Сабантуй.**

Актаныш муниципаль районы Чуракай
төп гомуми белем бирү мәктәбе татар теле һәм
әдәбияты укытучысы Салахов Рамил Җәмигънур улы

*I.Кереш.*

Кеше туа... Уңдырышлы җиргә төшкән бөртек кебек, ул, тамыр җибәреп, якыннарын сөендереп үсеп китә алырмы, җимешләрен биреп куандырырмы, әллә инде рәхимсез җилләргә эләгеп, әрәм булып юкка чыгармы? Бу сорау- мәңгелек. Борынгы төрки бабаларыбыз да, безнең кебек, тынычлыкта, бәла-казасыз яшәргә омтылганнар. Әледән-әле чыгып торган бәла-казадан котылу юлларын эзләгәннәр. Алар сагалап торган куркынычларны да, уңышларын да янәшәдәге нindидер яман һәм яхшы көчләрдән килә дип исәпләгәннәр. Борынгы бабаларыбыз, тормыш вакыйгаларын аңлату белән бергә, тормышларын җиңеләйтү өчен, махсус кагыйдәләр дә дә уйлап тапканнар. Мәсәлән, кеше ялгызы гына кара урманга керсә, аны Шүрәле кытыклап үтерә, дигәннәр. Я булмаса, караңгы төшкәч, ялгызың гына су коенырга керсәң, су анасы ала, дигәннәр. Чөнки кеше алай-болай суга кереп бата башласа, кичкә таба елга буенда аңа беркем дә ярдәм итә алмый бит, ул тончыгып үләргә мөмкин. Нәтиҗәдә, бала адашмый һәм суга батмый исән кала. Ә инде бабаларыбыз, кабиләләргә җыелып, бер урынга төпләнеп утыргач, кешеләрнең борчылу сәбәпләре үзгәрә. Моңа кадәр төп бурыч табигать көчләрен аңлап җиңү булса, хәзер инде яңа төзелгән җәмгыятьне дә саклап калырга, аны үстерергә кирәк була. Аерым кешеләрнең һәм гаиләләрнең язмышы хәзер җәмгыять иминлегенә бәйле булганга, халык үзенең көчен җәмгыятьне ныгытуга багышлый. Җәмгыять тотрыклы булуы белән көчле. Ул үзенең иң зур байлыгын- күп буыннар туплаган тормыш тәҗрибәсен- яңа шартларда да саклап калу өчен көрәшә, буыннан буынга тапшыра. Кешеләр көндәлек тормышта мөмкин кадәр азрак ялгыш ясарга тиешләр. Башкалар ясарга өлгергән ялгышны кабатламасаң, тормышта күп мәшәкатьтән котылырга мөмкин. Ләкин моның өчен башкалар ялгышын белергә кирәк. Шул тәҗрибәне халык хәтерендә сакланырлык җыйнак, тәэсирле итәрлек хикмәтле итеп чараларга, әсәрләргә әйләндергән. Шулай итеп йолалар, гореф-гадәтләр формалашкан. Әгәр татар теленең аңлатмалы сүзлегенә (3 томда, Казан, Татарстан китап нәшрияты) күз салсак, **йола** төшенчәсенә болайрак аңлатма бирелгән:

**йола** *и.* 1. Теге яки бу халыкның яшәешенә борыннан кереп урнашкан тормыш-көнкүреш традицияләрен яки дини канунннарны үтәүгә бәйләнешле тәртип һәм гадәтләр; гореф-гадәт. *Туй йоласы.* Карл Федорович. *Татар йолаларын белүдә без бик наданнарбыз икән әле, Насыйр Хөсәенович.* М.Гали.

2.Күпчелек тарафыннан кабул ителеп, гадәткә кереп киткән нинди дә булса күренеш. *Хәзер инде кыз ябыштырып чыгару йола булып китте..* Г.Камал.

**Гореф-гадәт.** җый. И. 1. Билгеле бер халыкның тарихи үсеш традициясе белән килә торган, көнкүрешкә караган яки дини йолалар. *Татар халкының этнографиясе, гореф-гадәтләре һәм йолалары белән кызыксынып йөри торган бу кызыклы профессор белән Габденнасыйр ... Ибраһим Хәлфин өендә танышкан иде.* М.Гали.

2. Гадәт, тәртип. *Сөләйман бу "кафе"да еш кына булганлыктан, анда мондагы барлык гореф-гадәт таныш иде.* К.Тинчурин.

Илебез капиталистик юнәлеш белән кереп киткәнлектән, һәр кеше, җәмгыятьтән аерылып, бары тик үз-үзен генә, үз гаиләсен генә кайгыртуга күчкәнлектән, соңгы елларда буыннан-буынга, чорладан-чорга күчә барган гореф-гадәтләр чылбыры өзелде. Бүгенге идеология үзгәргән авыр, болганчык заманда татар халкының күпгасырлык тормыш тәҗрибәсеннән алынган гореф-гадәтләренең, йолаларының искереп тоныклана баруы белән аларның рухи кыйммәтләренең югалу проблемасы килеп туды. Һәм шуңа күрә мин XX гасыр азагы XXI гасыр башы балалар шагыйрьләре иҗатына таянып, халкыбызның иң гүзәл йоласы- хезмәт бәйрәме- Сабантуй бәйрәменә тукталдым. Максатым- халкыбызның күп гасырлар дәвамында җыйналган рухи хәзинәсен, гореф-гадәтләрен, зур әхлакый кыйммәткә ия булган мәдәни чараларын бүгенге буын укучысына тапшыру.

*II.Төп өлеш.*

Сабантуй – элек-электән халкыбызның һәрчак яратып, зур күтәренкелек белән үткәрелә торган олы бәйрәме ул. Халык йолаларын өйрәнүче этнографлар да аның белән күптән кызыксынганнар, ләкин аларның төп игътибары нигездә мәйдан өчен бүләк җыю тәртибенә һәм мәйданның үзенә, аннары җиңүчеләрне бүләкләү мизгеленә юнәлтелгән. Язгы йолалар исә сабантуй белән бәйләнештә каралмаганнар, аның белән берлектә өйрәнелмәгәннәр. Сабантуй исә иртә яздан башлап үткәрелә торган тулы бер йолалар, күңел ачулар, ярыш-бәйгеләр тезмәсе ул. Алар язын кар эреп җир ачыла

башлаган көннәрдән алып язгы чәчүгә кадәр үткәрелгән. Бу бәйрәмнең башка үзенчәлекләре дә бар: аны үткәрү өчен төгәл билгеләнгән календарь көн генә түгел, атнаның аерым көне дә юк. Монда бөтенесе елның нинди булуына, карның ничек эрүенә һәм җирнең чәчү өчен кирәк дәрәҗәдә әзер булуына бәйле. Моны авыл картлары киңәшләшеп хәл иткәннәр, бәйрәмне үткәрү турында авыл кешеләренә әйткәннәр. Сабантуй түбәндәге тәртиптә үткән:

- халыктан җыйган азык-төлектән балаларга ботка пешереп ашату (карга боткасы, дәрә боткасы);
- балаларның манган йомырка җыюы;
- ат менгән егетләрнең йомырка җыюы һәм аны пешереп ашавы – сөрән сугу;
- танымаслык булып киенгән ирләрнең йомырка җыеп йөрүе (җәяүле сөрән);
- мәйдан өчен бүләк җыю;
- мәйдандагы ярыш-бәйгеләр;
- яшьләрнең кичке уены.

Сабантуй – олы бәйрәм һәм аңа хәзерлек алдан ук башланган. Хатын-кызлар өй җыештырган, бөтен нәрсәне чистартканнар. Ирләр исә ишегалдын, урам тирәләрен себергәннәр, чүп-чарны җыештырганнар, бәйрәм көнгә лаек нигъмәтләр әзерләгәннәр. Бу көнне яшьләр уңганлыкта-булганлыкта сыналганнар, үзләренә пар сайлаган, күз атып йөргән ярлары алдында “имтихан” тотканнар. Сабантуй батырына уңган килен бүләге- чигүле сөлге әзерләнгән.

Мин бүгенге хезмәтем белән тулы йолалар циклының бары тик берсе- бәйрәм көнен тасвирлаган шагыйрьләребез иҗатын бәян итәргә булдым. Сабантуй турында үзләренең әсәрләрендә берничә җөмлә белән генә булса да тукталмаган язучы, шагыйрь бар микән? Чөнки ул үзенең иң гүзәл, саф мизгелләре белән кабатланмас яшьлек хатирәләре булып безнең күңелләргә кереп урнашкан. Зур тормыш юлына аяк басарга хәзерлек этабы ул сабантуй, дисәк тә дөрес булыр. Ә шагыйрьләребез иҗатына якынрак килсәк, яраткан балалар шагыйре Шәүкәт Галиевнең “Сабантуйда җиңелгән малай” шигырендә җитмеш бабадан калган көрәшкә ашкынып чыккан бер кечкенә малай тасвирлана. Ярыш-ярыш инде, үзеннән зуррак малайга туры килеп, җиңелү ачысын да татырга туры килә:

...Мәйданга беренче керде,
Беренче бирешүе,
Горур атлап чыгып килә,
Сизелми килешүе.
Җиңелү гарлеген бүген
Егетләрчә җиңәчәк.
Аһ итәр әле Сабантуй,
Котлар аны киләчәк!

Фәнис Яруллинның “Бүген бездә сабантуй” шигыренә игътибар итсәк, татар халкының кунакчыллыгына, үз бәйрәменә башкаларны да чакыруына, кунак итә белүе белән горурланасың:

Карасагыз — бәйрәм бар,
Сусасагыз — әйрән бар.
Ял итәрсез — арсагыз,
Үкенмәссез — барсагыз.

Ә безнең якташыбыз- Сөн буе егете- балаларның яраткан шагыйре Роберт Миңнуллинның “ Сабантуйда “ шигырендә бәйрәмдәге бер ярыш мизгеле- колга башына менү ярышы сурәтләнә. Һәм үзенә генә хас юмор белән гадәтенчә шартып та ала: колга башына менгәндә менгән иде дә безнең малаебыз, төшүе менүгә караганда да кыенрак икән бит! Дан-шөһрәте дә кирәкми:

Ычкынды, җиргә очты,
Йоны гына — учымда.
Әтәч урынына мин
Калдым колга очында.
Кирәкми әтәчегез,
Кирәкми бүләгегез —
Мине алырга гына
Менегез берәрегез!

Шулай ук бәйрәмнең тагын бер үзенчәлеген искәртә Роберт Мөгаллимович үзенең “Сабан туен күрми калганмын” шигырендә- ул да булса, сабантуй бәйрәме ул- күптән туган авылына, әти-әнисе янына, туганнары, дуслары янына кайтырга теләп тә кайталмый йөргәннәрнең очрашу бәйрәме дә икән бит!

Якташыбыз Ләбиб Лерон “Сабан туе, сабан туе...” шигырендә безнең бәйрәмнәр, йолалар белән таныш булмаган башка берәр планета кешесе күрсә, шаккатыр иде. Әле мин хәзер дә шаккатудан арына алмадым, ярыш мизгелләрен күзәтеп, ди шагыйрь:

Әгәренки-мәгәренки,
Көтмәгәндә алай-болай,
Очар тәлинкәдән ялгыш
Төшеп калса берәр малай…
Нинди булыр икән уе —
Күрсә безнең сабан туен?..

…Торыр микән хәйран калып? ...
Нәп-нәкъ шулай булыр иде,
Миндәй хәйран калыр иде.

Балалар шагыйрьләре генә түгел, инде әйтеп узуымча, яраткан бәйрәмебез турында язмаган берәр язучыбыз, шагыйребез бар микән? Лена Шагыйрьҗанның "Яшә, Сабан туе" шигырендәге түбәндәге сүзләре:
Синең хакка пешә
Бәлеш, коймаклары.
Сиңа башын ия
Хуҗа, кунаклары,
Эльмира Шәрифуллинаның "Сабантуй" шигырендәге
Сабантуймы, Сабантуй —
Уеннар туе бит ул,
Тәм-томнар сые бит ул,
Җиңүләр уе бит ул,-сүзләре безне кесә тулы көмеш акчаларыбыз белән төрле тәм-томнар белән сыйланып йөргән балачагыбызга кайтарып куя.

Мөдәррис Әгъләмов "Сабантуй" шигырендә бу көнне илен, халкын, милләтен яратучы яшь буын тәрбияләнүен күрә:
*Сабантуйларда да алга карый халык,*
*Көрәштерә башлый нәниләрдән алып.*

Сөлгеләр тотыла, һәр авыл
Батырын күзәтә, билгеле...
Мәйдан күк кысыла йөрәкләр:
— Бирмә биленңне!
— Бирмә-ә-ә...
Дошманнар таптаса җиреңне,
Сорамый: «Син батыр идеңме?»
Мәйдан күк кысыла бар халык:
— Бирмә илеңне!
— Бирмә!

Азнакай шәһәрендә яшәп иҗат итүче Резеда Шәрипованың "Бүген бездә сабантуй!" дип исемләнгән шигырьләр циклына бу бәйрәмнең, халык әйтмешли, энәсеннән җебенә кадәр барлык нечкәлекләре бәян ителгән шигырьләре тупланган. Сабыйның бәйрәмгә бару вакытын ничек кенә җиткерергә белмәве, иртән торуына тәмле ис бөркелеп торуы, кунаклар килүе- һәммәсе-һәммәсе дә бик урынлы кулланылган дияр идем.

Кунаклар килгәнче мин дә
Торып урынны җыйдым.
Чәчемне тарап, өр-яңа
Күлмәгем киеп куйдым.
Үтми дә үтми һич вакыт,

Ничек түзеп торасы,
Әллә инде сәгать угын
Алга таба борасы?

Базарны хәтерләткән сәүдә нокталарын да Резеда Шәрипова образлы итеп сурәтләп китә:

Елан кебек бормаланып
Тезелде озын чират.
Куандырды сатучылар
Туңдырма белән сыйлап.

Көрәш ярышы, колгага менү, капчык сугышы, аркан тартышу, чиләк белән су ташу, гер күтәрү, катыктан акча эзләү, чүлмәк вату, кашык кабып йөгерү, бигрәк тә капчык киеп йөгергән малайның егылып та еламавы, үҗәтлек белән һаман да башкалар артыннан чабуы бик оста тасвирланган:
Яшел чирәмгә сузылып
Ятканны сизмәдем дә,
Башкалар узып киткәнен
Күрдем дә, күрмәдем дә!
Сикереп торып, ачудан
Томрылдым алга табан.
Үҗәтлек бушка китмәде,
Беренче килдем – арттан!

“Чабышкылар килә!” шигыре атларга карата бабаларыбыздан ук килгән мәхәббәт белән сугарылган. Азактан килгән атка да бүләк бирелүен сокланырлык итеп тасвирлый.

Тояклардан утлар чәчеп,
Чабышкылар килә.
Җиңү тәмен иярләгән
Ат та хәтта белә!
Муенына чиккән сөлге
Салу белән аның,
Җиденче катына күкнең
Аша ярсу җаны.
Артта калган бахбай гына
Бик тә, бик тә боек,
Күзләренә яшь эленгән
Җиңелгәнен тоеп.
Чәчәкләрдән тәкыя үреп
Килдем дә янына,
Сыйпап, назлап ялларыннан
Элдем муенына.
Башын чөеп аргамагым
Кешнәп аваз салды.
Мөгаен, ул бүләгемнән
Бик канәгать калды.

Ә инде бәйрәм гармунсыз буламы соң? Татарча җырлап та биемәгәч, нинди Сабантуй булсын, ди, инде? Резеда Шәрипова татарның дәртле бию көйләренә дә урын биргән:
Өздереп уйный гармун,
Һәр тарафта уен-моң.
Килешеп тора көе,
Уртага чыгып бие!
Ялындырып тормачы,
Чакырганны бормачы!
Бие-бие җилкенеп,
Мәйдан торсын селкенеп!
Осталыгың күрсеннәр:
-Их, шәп баса!-дисеннәр.

Татар халкы элек-электән тырышып эшли дә белгән, башкаларны шаккаттырып, сокландырырлык итеп ял да итә белгән. Әм ялның да әле нинди ен! Яшь буынны шул ял вакытлары белән гадел дә, горур да, көчле дә, елгыр да, җитез дә, пөхтә дә, тырыш та булырлык итеп тәрбияли дә белгән. Милли бәйрәмебез турында әсәрләр бик күп һәм аларның барысына да тукталу мөмкин дә түгел. Ләкин

шушы кыска гына күзәтүдән дә бәйрәмнең максаты, аның яшь буынны тәрбияләүдәге иксез-чиксез кодрәте күренеп тора.

*III.Йомгак.*

Бүгенге идеология үзгәргән авыр, болганчык заманда татар халкының күпгасырлык тормыш тәҗрибәсеннән алынган гореф-гадәтләренең, йолаларының искереп тоныклана баруы белән аларның рухи кыйммәтләре югала, дигән идем. Фәнни-эзләнү эшен язу чорында түбәндәге нәтиҗәгә киләбез: чыннан да бик күп йолалар кулланылмый башлаган дәвердә арада иң сакланганы һәм тәрбияви әһәмияте югалмаганы әлегә- Сабантуй.

Әлбәттә, борынгыдан бүгенге көннәргә кадәр сакланып килгән милли бәйрәмебез турында әсәрләр күп, әле киләчәктә дә иҗат ителер, чөнки бәйрәм үзе дә эчтәлеген еллар үтү белән үзгәртә, өстәмә ярышлар кертелә, ярыш кагыйдәләре үзгәрә, яңа буын шагыйрьләре, язучылары үсеп чыга. Ләкин иң әһмиятлесе- балалар шагыйрьләре иҗаты аркылы халкыбызның күп гасырлар дәвамында җыйналган рухи хәзинәсе, гореф-гадәтләре, зур әхлакый кыйммәткә ия булган мәдәни чаралары бүгенге буын укучысына, балаларга тапшырылуы.
Инде дөнья күргән әсәрләр- басылып, укучысына җиткерелгән әсәрләр- бер-берсен тулыландырып, сабантуй күренешләрен бөтен барлыгы белән тасвирлыйлар. Киләчәктә дә татар милләтен еракларга танытуда үз өлешен кертеп, милли бәйрәмебез озын гомерле булсын, аны тагы да еракларга ишеттерерлек әсәрләр иҗат ителеп, балаларыбызны тәрбияләсен иде дигән теләктә мин фәнни эшемне тәмамлыйм.

*IV. Файдаланылган әдәбият исемлеге.*

1. Әдәбият: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 9 нчы с-фы өчен дәреслек. /А.Г.Яхин.-Казан: “Мәгариф”, 2006./
2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге./3 томда: Т.1.,2.-Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1977./
3. Галиев Ш. Сабантуйда җинелгән малай: шигырь // Җәлалова, А.Татар әдәбияты: хрестоматия.- Казан: ТаРИХ, 2003.- Б.70-71
4. Мирза Мөхәммәт. Сабантуй: шигырь // Мирза, Мөхәммәт. Киек каз юлында: шигырьләр, газәлләр, поэмалар.- Казан, 2003.- Б.294-298.
5. Рәхим, Г. Сабан туе: шигырь // Рәхим, Г. Сайланма әсәрләр. 2 том. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2003.- Б. 199.
6. Әюп, Х. Сабантуй: шигырь // Татарстан.- 1996.- № 8.- Б.69.
7. Миңнуллин Р.М. Сабантуй бүген бездә!; Тәкә; Кульяулык; Чүлмәк вату: шигырьләр // Р.М. Миңнуллин. Күчтәнәч: шигырьләр.- Казан: Мәгариф, 1995.- Б.68-70.
8.Зәйнашева Г. Сабан туенда: шигырь / Г. Зәйнашева // Аҗаган.- 1994.- № 1.- Тышл. Б 3
9.Рәхмәт Б. Сабантуенда: шигырьләр, әкиятләр, табышмаклар һәм башваткычлар.- Казан, 1977.- Б.7-15.
10. Роберт Миңнуллин. Сабантуйда Иң матур сүз : ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен хрестоматия.- Казан : Мәгариф. 2000.- 335 б.